Республика Татарстан
Исполнительный комитет
Светлоозерского
сельского поселения Заинского
муниципального района

ул. Фардеева, д.15, с. Светлое Озеро,
Заинский район, 423538

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлегенең
башкарма комитеты

Фардеев урамы, 15нче йорт, Якты Күл
авылы, Зәй районы, 423538

Телефон, факс 68-2-88. Электронный адрес: Svoz.Zai@tatar.ru, сайт:

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
от 09.12.2021 ел.

КАРАР
№ 19

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160^2 статьясы 4 пунктының дүртенче абзацы нигезендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлегенең башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар (2022 елга) план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

3. Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Башкарма комитет
җитәкчесе **З. З. Мөхтәров**

Татарстан Республикасы
Зәй муниципаль районы
Якты Күл авыл җирлегенең
башкарма комитетының
09.12.2021 ел 19 номерлы
карары белән расланган.

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеге

Бюджет классификациясе коды		Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторы исеме/ Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты керемнәре төре (төрчәсе) кодының исеме
керемнәрнең баш администраторы	Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты керемнәре төре (төрчәсе)	
1	2	3
833	Зәй муниципаль районы финанс-бюджет палатасы	
833	0 10 50201 13 0000 510	Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты акча средстволарының башка калдыкларын арттыру
833	0 10 50201 13 0000 610	Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты акча средстволарының башка калдыкларын киметү

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында»
Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Башкарма комитеты карар проектына аңлатма язуы

«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең Башкарма комитеты карар проекты (алга таба – карар проекты) «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр керту турында» 2021 елның 1 июлендәге 251-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясы 17 пунктын гамәлгә ашыру максатларында әзерләнде, аның нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясы 4 пунктның 4 абзацы белән тулыландырылды, ул җирле администрация тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген раслауны күздә тота.

Карар проекты җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторын җирле администрация органнарына беркетүгә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 16 сентябрендәге 1569 номерлы карары белән расланган җирле бюджет кытлыгын финанслау чыганакларының төп администраторлары исемлеген раслауга карата гомуми таләпләрне исәпкә алып эшләнгән.

Югарыда күрсәтелгән федераль законның 4 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.2 статьясындагы 4 пункты нигезләмәләре Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегенең 2022 елга һәм 2023 - 2024 еллар (2022 елга) план чорына бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Карарны гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Якты Күл авыл җирлеге бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.